| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.02.2026 г. Казань № 5-2/соц-2026

«Социаль няня» хезмәтен күрсәтүгә тариф билгеләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 13 октябрендәге 827 номерлы «Коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан «Социаль тәрбияче» хезмәтен күрсәтү» пилот проектын гамәлгә ашыру турында»гы, 2026 елның 21 гыйнварындагы 25 номерлы «Социаль тәрбияче» хезмәтен күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне һәм «Социаль тәрбияче» хезмәтен күрсәтүгә финанслауның җан башына нормативларын раслау һәм «Социаль тәрбияче» хезмәтен күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм «Социаль тәрбияче» хезмәтен күрсәтүгә финанслауның җан башына нормативларын билгеләү турында»гы карарлары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты Идарәсенең 2026 елның 11 февралендәге 3-ПР номерлы утырыш протоколы нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР ИТӘ:

1. «Социаль няня» хезмәтен күрсәтүгә тарифны әлеге карарга кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 нче пунктында билгеләнгән тариф үз көченә кергән карарның көненнән башлап 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В. Гайнетдинов

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.02.2026 № 5-2/соц-2026
карарына кушымта

«Социаль няня» хезмәтен күрсәтүгә тариф

| № | Хезмәт төре | Үлчәү берәмлеге | Тариф |
|---|---|---|---|
| 1. | «Социаль няня» хезмәтен күрсәтү | сум/сәгать | 399,48 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге